КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 11 ноябрь г.Казань № 928

2026 елга Татарстан Республикасында халыкның җан башына һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен раслау турында

“Россия Федерациясендә яшәү минимумы турында” 1997 елның 24 октябрендәге 134-ФЗ номерлы, 2024 елның 29 октябрендәге 367-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору, Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану һәм 2025 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында” 2021 елның 26 июнендәге 1022 номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Чираттагы елга Россия Федерациясе субъектларында бер кешегә исәпләнгән һәм халыкның төп социаль-демографик төркемнәре буенча яшәү минимумы күләмен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында” 2021 елның 26 июнендәге 1022 номерлы карары, “Татарстан Республикасында яшәү минимумы турында” 2005 елның 20 июлендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2026 елга Татарстан Республикасында яшәү минимумы күләмен халыкның җан башына исәпләгәндә – 16 098 сум, эшкә яраклы халык өчен – 17 547 сум, пенсионерлар өчен – 13 844 сум, балалар өчен 15 615 сум итеп расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин